**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8133**
**05.12.2024**

«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 1 өлешенең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 22 мартындагы 1459 номерлы Карары үз көчен югалткан дип таныrга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка  йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 декабрендәге
8133 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен
производство-техник тәэмин итү үзәге»
муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 622,14 |
| 2. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 12,44 |
| 3. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1424,29 |
| 4. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 28,49 |
| 5. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1961,98 |
| 6. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 39,24 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева